# Исем сүз төркемен гомумиләштерү

(4нче сыйныфның  татар төркеме)

elenaranko.ucoz.ru

- Исәнмесез,саумысез,укучылар!
- Кәефләрегез ничек?
- Кояшлы иртә кебек.
- Татар телен , әнкәм телен
- Өйрәнергә дип килдек!

-Әйдәгез, бер-беребезгә елмаеп карыйк һәм хәерле эш сәгате телик!






elenaranko.ucoz.ru

http://www.youtube.com/ «Бумеранг добра»(2мин.)

elenaranko.ucoz.ru

“Яхшылык күрәсең килсә, яхшылык ит!”

elenaranko.ucoz.ru







# Исем
















elenaranko.ucoz.ru

# Үзбәя картасы

1нче баскыч:

-Үз эшем, җавапларым белән канәгать түгел - дигәнне аңлата.

2нче баскыч:

- Яхшырак та эшли,җавап бирә ала идем - дигәнне аңлата.

3нче баскыч:

-Кулымнан килгәннең барысын да эшләдем - дигәнне аңлата.




elenaranko.ucoz.ru

## Бирем:№1 Парлап эшләү

*Ролик караганда язып алган сүзләр белән фильм буенча дәфтәрегезгә ике җөмлә язарга.*




elenaranko.ucoz.ru

## Бирем:№2

*Л.Толстойның“Розка” хикәясеннән алынган өзек буенча эш. Тексттагы җөмләләрне дөрес итеп урнаштырырга һәм төшеп калган кушымчаларны куеп дәфтәргә язарга.*



elenaranko.ucoz.ru

# Розка

*Малайлар килделәр дә, берсен өй... алып кердeләр. Ишегалды... Розка дигән эт яши. Печән... аның балалар... уйный. Малайлар көчек... Розка... бирделәр. Розка, бер көчек(г).. эзләп, улый башлады. Ул аны арка...... капты да оя....... илтеп куйды.Ул аны мич баш...... тапты, тик улау... туктамады.*

**Кушымчалар:*-нда, -дә, -ы, -гә, -ен, -ыннан, -дан, -не, -га, -сыннан,-сына***




elenaranko.ucoz.ru

## Розка

Ишегалдын<u>да</u> Розка дигән эт яши. Печән<u>дә</u> аның балалар<u>ы</u> уйный. Малайлар килделәр дә, берсен өй<u>гә</u> алып керделәр. Розка, бер көчег<u>ен</u> эзләп, улый башлады. Ул аны мич башы<u>ннан</u> тапты, тик улау<u>дан</u> туктамады. Малайлар көчек<u>не</u> Розка<u>га</u> бирделәр. Ул аны арка<u>сыннан</u> капты да оясы<u>на</u> илтеп куйды.



elenaranko.ucoz.ru

# Исемнәрнең килеш белән төрләнеше

| Килешләр | Кушымчалар |
|---|---|
| Баш килеш | - |
| Иялек килеше | -ның/-нең |
| Юнәлеш килеше | -га/-гә, -ка/-кә |
| Төшем килеше | -ны/-не |
| Чыгыш килеше | -дан/-дән, -тан/-тән<br>-нан/-нән |
| Урын-вакыт килеше | -да/-дә, -та/-тә. |

elenaranko.ucoz.ru

# Ял минуты.

## Серле тартма уены.



elenaranko.ucoz.ru

*1.Кайсы шәһәрдә аш пешереп була?*

**Казан**

*2.Укырга да өйрәтә, язарга да өйрәтә, аны белә һәр кеше, ул була ...*

**Укытучы**

*3.Аягы суда, башы көн дә.*

**Төнбоек**

*4.Кем үз оясы өстендә йөри?*

**Әкәм - төкәм**

*5.Кызыл төймә таптым, авызыма каптым.*

**Җир җиләге**

elenaranko.ucoz.ru

# Исемнәрнең ясалышы

1.Тамыр исемнәр: төш, кул, авыл.

2.Ясалма исемнәр: ташчы, куллы, авылдаш.

3.Тезмә исемнәр: Киек Каз Юлы, Кура җиләге.

4.Парлы исемнәр:ата-ана,аң-белем.

5.Кушма исемнәр: кулъязма, урынбасар.

6.Кыскартылган исемнәр:КДУ,КАМаЗ.


elenaranko.ucoz.ru

# Бирем:№3 Төркемнәрдә эшләү

*Бирелгән рәсемнәрдән күплек сандагы исемнәрне дәфтәргә язарга.*

**1 төркем** **2 төркем** **3 төркем**








elenaranko.ucoz.ru

# Бирем:№4

## (флипчарт тактасында эш)

*Флипчарттагы агач рәсеменнән берәм-берәм чыгып, я кул, я йөрәк рәсемен алырга һәм артындагы дәреслектәге 120 нче күнегүдән алынган җөмләләрне татарчага тәрҗемә итеп, дәфтәргә язып куярга.*




elenaranko.ucoz.ru

# Исемнәрнең тартым белән төрләнеше

| | Тартым кучымчалары | |
|---|---|---|
| | Берлек сан | Күплек сан |
| 1 зат | -ым/-ем/-м | -быз/-без//-ыбыз/-ебез. |
| 2 зат | -ың/-ең/-ң | -гыз/-гез//-ыбыз/-егез. |
| 3 зат | -сы/-се/-ы/-е | -сы/-се/-лары/-ләре,-ы,-е. |

elenaranko.ucoz.ru

**Бирем:№5**


**Җөмләдә бирелгән исемгә морфологик анализ ясарга.**

Үрнәк: *Әтием – уртаклык исем, берлек санда, I зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән,баш килештә,җөмләдә ия.Тамыр исем.*

elenaranko.ucoz.ru

# Бирем:№6 Төркемнәрдә эшләү

## Исем сүз төркеме буенча кластер төзү




elenaranko.ucoz.ru

## Өй эше.

1.Мәҗбүри өй эше (репродуктив) - дәреслектәге 127 нче күнегү.Төшеп калган кушымчаларны куеп, күчереп язарга,өч исемне сайлап алып морфологик анализ ясарга.

2.Ярым иҗади (конструктив) -“Сабантуй” газетасыннан исемнәр кергән 5 җөмлә язарга.

3.Иҗади-"Борын-борын заманда Морфология патшалыгында Исем дигән сүз төркеме яшәгән икән......" дип башланган әкиятне дәвам итәргә.




elenaranko.ucoz.ru



***Әй бит дөнья шундый матур үзе,***
***Каш җыермый гына карасаң.***
***Һәрберебез өчен кояш чыга,***
***Һәрберебез өчен таң ата.***
***Һәрберебез зур бәхеткә лаек,***
***Һәрберебез кеше ләбаса.***
***Яшәү шундый җиңел булыр иде,***
***Һәркем әгәр башка берәүнең дә***
***Кеше икәнлеген аңласа.***
***Нинди генә авыр вакытлар булса да,***
***кеше булып кала белергә кирәк!***

elenaranko.ucoz.ru

- Кулланылган әдәбият
- Гомуми белем бирү эчтәлегенең фундаменталь төше - Фундаментальное ядро содержания общего образования: / под ред. В. В.Козлова, А.М.Кондакова. – М.: Просвещение, 2009.
- Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова.Татар теле.1-4 сыйныфлар өчен : укытучы өчен методик кулланма.- Казан:Татар.кит.нәшр., 2014.
- Мозаффарова М.Г. Тәгълим-тәрбия процессын оештыруда милли мәгърифәтчелек идеяләрен гамәлгә кую: гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре өчен тәкъдимнәр. М.Г.Мозаффарова, -Казан. ТР Мәгарифне үстерү институты. 2016.
- Интернет ресурслар:
- Сабыем. Балалар,ата-аналар,тәрбиячеләр өчен сайт
- http://www.youtube.com/ «Бумеранг добра»
- http://www.dagorlenok.ru/upload/iblock/e1d/e1d7eaa4acd2af3779aaf1445138cc89.jpg
- http://www.psycholo gos.ru/images/ee0dd2e146c8c4db53f104cbab270286.jpg
- http://1.bp.blogspot.com/zY4C8kfAmWI/U8_UPdKD5yI/ pg
- http://wbd.ru/images/old-news/87816


elenaranko.ucoz.ru